## ГИМНАЗИЯ ЯШЬЛӘРЕ МӘЙДАНЧЫГЫ

***Лиана Хәбибуллина,***

***Мөслим гимназиясенең 9 нчы б сыйныфы укучысы***

## ГОРУР ХАЛКЫМ

Йортлар яна, яна зур шәһәрләр,

Яна анда иген кырлары...

Бөтен жирне кара төтен баскан,

Ишетелми тургай җырлары...

Сугыш узган җирдә хәрабәләр,

Кала бары җансыз, тынсызлар.

Фашист-явыз бик тә мәрхәмәтсез,

Ерткычтан да алар кансызлар.

Бозга катып, утта янсалар да,

Безнең халык башын имәгән.

Вакыты белән артка чигенсә дә,

Җиңүләрдән өмет өзмәгән.

Бар ышаныч булган тик җиңүдә,

Халык безнең якта булганга.

Алны-ялны белми сугышканнар,

Җаннар нәфрәт белән тулганга.

Килгән ул көн, килгән Җиңү көне,

Язлар бүләк иткән Җиңүне.

75 ел ветераннар көтә

Һәр ел саен язлар килүне.

Бәйрәм җиткәч, алар яшәрәләр,

Медальләрен таккач түшләргә.

Тагын бик күп еллар безнең сафта

Насыйп булсын юллар үтәргә.

**ҖИҢҮ КӨНЕ**

Җиңү көне якынлашкан саен
Искә төшә бабам үткән юл.
Ядрә шавы, ачлык-ялангачлык
Барысына да түзгән солдат ул.

Фашист-мәлгунь шакшы итек белән
Чәчкә болыннарны таптаган.
Сыра эчеп көн дә бәйрәм иткән,
Ә җанына рәхәт тапмаган.

Сабыйларның ачы күз яшьләре
Чишмә булып юлын бүлгәннәр.
Ил өчен дип япь-яшь ир-егетләр,
Аягүрә басып үлгәннәр.

Хәрабәләр калган явызлардан,
Яндырганнар, тар-мар иткәннәр,
Ә аналар кырда көн-төн эшләп,
Җиңү көнен зарыгып көткәннәр.

Килгән ул көн, ямьле май аенда
Кояш чыккан болыт артыннан.

Уйнаганнар көлеп, бәйрәм итеп,

Күз яшьләре тамган барсыннан.

Җитмеш  биш ел инде Җиңүгә дә,

Ә күңелдә күпме яралар...

Балаларын көтеп алалмыйча

Күзен йомган күпме аналар.

# ТУГАН ҖИРДӘ ТАҢ АТА

Кояш көлә, тан ата,
Чирәмнәргә чык ята.
Кояшка елмайган булып,
Чәчәкләр күзен ача.

Кошлар да уяналар,
Сайрашып куаналар.
Канатларын кага-кага,
Назлашып юаналар.

Чишмәләр челтериләр,
Ташларны иркәлиләр.
“Туган җирдә бик тә матур,
Читләргә китмә”,  - диләр.